КАДИРОВА Э.Х.
(ТДГПУ доценты)

# Г.ТУКАЙ ИҖАТЫНДА БӘХЕТ МӘГЪНӘСЕ

Г.С.Әмиров, Г.Тукай шигырьләрендә бәхет, сәгадәт, икъбаль, талигъ синонимнары бәхет мәгънәсендә кулланылалар дип күрсәтә [Әмиров 1971, 58]. Бу тамырлардан ясалган бәхетле, сәгадәтле, бәхетсез, талигасыз, бәдбәхет, мәсгуд, мәсгудийәт, бәхтияр сүзләре дә шагыйрь иҗатында еш очрыйлар. Бу сүзләр татар теле сүзлекләрендә урын алганнар:

Бәхет – 1. Тулы канәгатьләнү халәте һәм хисе; 2. Уңыш (эштә, тормышта һ.б.); 3. Бәхет чыганагы, бәхет китерүче [ТТАС 1977, 211].

Икъбаль (гарәп)– 1. Эшнең алга баруы; 2. Бәхет алга китү, бәхетле булу; 3. Бәхет, уңыш; 4. Каршы алу [ГТРАС 1965, 154].

Мәсгуд – иск. китап. Бәхетле, бәхетле булу, рәхәтлек [ТТАС 1979, 420].

Сәгадәт – бәхет (ТТАС 1979, 707). Сәгадәтле – бәхетле [ТТАС 1979, 707].

Талиг - уст. книжн. Доля, счастье, рок, удел [ТРС, 1966, 512].

Бәхет төшенчәсен борынгы төрки телдә үк берничә сүз белдергән. Кот– гомумтөрки сүз. Борынгы төрки сүзлектә аның түбәндәге мәгънәләре теркәлгән: qut – 1. счастье, благо, благодать, благополучие; удача, успех; счастливый удел. 2. достоинство, величие [ДТС 471].

Бәхет – гарәп сүзе. Шулай ук борынгы язма истәлекләрдә үк кулланыла [ДТС 89].

Бәхет – бик киң төшенчә. Ул тышкы факторлар белән бәйле хис булганлыктан, һәрвакыт нинди дә булса конкрет объектка юнәлгән була. Тукай иҗатында бәхетнең Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә бирелгән беренче мәгънәсен билгеләүче төп шартлар төрле.

Г. Тукай балаларга багышлап язылган күп кенә әсәрләрендә бәхет төшенчәсен мәгърифәт белән тиңли:

Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә,

Мөгаллимне олуг күрсә, белергә кушканын белсә;

Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга,

Уенга салмас ихлас- менә бәхте аның шунда.(Бәхетле бала)

И каләм, сәндин кәлүр һәп бәхтемез, икъбалемез;

Бәкләнүр дүрт күз илә лотфыңда истикъбалемез.(И каләм)

Шул ук вакытта авторның гыйлем алу белән бәхетне янәшә карамаган шигырьләре дә бар:

Ике юл бар бу дөньяда: бере будыр – бәхет эстәү;

Икенче шул: гыйлем гыйшкында булмак – мәгърифәт эстәү.

Синең кулда: теләрсәң – мәгърифәтле бул, бәхетсез бул

Вә яки бик бәхетле бул, ишәк бул, мәгърифәтсез бул. (Ике юл)

Шагыйрь иҗатында бәхетнең аерым мәгънәсе хезмәт белән туры килә:

Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә,

Аһ, оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә. (Эшкә өндәү);

Егет әйтә: мин күп нәрсә булып үттем,

Һәрберсеннән галилек һәм бәхет көттем;

Күрдем хәзер: эшкә һичнәрсә тиң түгел,

Эштән көчле нәрсә табу мөмкин түгел. (Япон хикәясе)

Г.Тукайның бәхет турында балаларга атап язган хикәясе дә бар. Анда да автор бары тик лаеклы хезмәт нәтиҗәсендә генә бәхеткә ирешеп булганлыгын ачыклый (Бәхет).

Күп кенә әсәрләрендә шагыйрьнең бәхете татар халкы, аның бәхете белән бәйле карала, ягъни халык аны тану – бәхет:

Бер заман яд әйләсә бильилтифат милләт бәни, -

Иштә будыр максадым, мәэмүл вә мәсгудиятем. (Милләтә).

Бәхтиярым – бәндәңи гөр итсәләр нисбәт сәңа. (Милләтә).

Шагыйрь милләт бәхете турында фикер йөрткәндә, милләт бәхете белән үз бәхетен янәшә күрә:

Тукай иҗатында кешелек ихтыяҗларын канәгатьләндерү - бәхетнең тагын бер мәгънәсе:

Нә дәүләт милләтә, нә бәхт вә талигъ,
Бу көз төньяктан улды шәмес талигъ. (Шигырь)

Калган мәгънәләрен дә санап үтик:

- тәхет:

Насыйп булса менә шушындый хан булу,-
Булыр иде шул вакытта бәхтем минем (Япон хикәясе).

- бәйсез тормыш итү:

Күбәләк җавапта: “Юк, бер дә көнләшмим, аның өчен, син никадәр югары очсаң да, бәйләүдә генә очасың; минемчә, мондый гомер итү бәхеттән бик ерак булырга тиеш”. (Кәгазь очыргыч).

- мәхәббәт:.

- байлык, муллык, мул тормыш:

- И дуст! Мин хәзер бик бәхетле, миннән хуҗа һәм Хатыны үзләренең җаннарын да кызганмыйлар; шөкер ходага, байлыкта, рәхәттә торамын, алтын-көмеш табаклардан гына ашыймын, ашап туйгач, кәефләнәм, Хуҗа хатыны илә уйный башлыйм. (Ике эт).

Бик юашлатты мине яшьрен сөюдән җан көю,
Бар иде булган чагым хәтта арсланнан кыю!
Һәр теләккә килде тәкъдирем белән бәхтем кире,
Мондый хәлгә сабриталмас, булса да адәм дию (Актык тамчы яшь)

“Ходаем, ник фәкыйрь иттең мине болай?
Рәхмәтең киң, мин бәндәңне кылсаң да бай;
Бүтәннәрдәй мин дә рәхәт сөрер идем,
Тынычлык һәм бәхет йөзен күрер идем”(Япон хикәясе)

Соңгы мисаллардан кешегә бәхет Ходайдан килә, дип уйларга мөмкинлек туа. Чыннан да, диахроник планда күзәткәндә бәхетнең семантик архетибы – язмыш, ягъни кешенең тормыш юлы, бәхете Аллаһ тарафыннан

бирелә. Бәхет Аллаһ бүләге була, кешенең үзеннән тормый, югары көч яки бирә, яки юк. Әмма алдагы юлларда шагыйрь бәхетле булу өчен үзеңә көч куярга кирәклеген ачык күрсәтә.

Әгәр син катле нәфес итмичә торсаң,
Җаныңны изгелек берлән тутырсаң,
Ачар ирде ходай бәхтеңне шаять. (Катиле нәфескә).

Димәк, кеше үз бәхетен үзе тудыручы булып санала.

Соңга таба бәхет сүзенең "уңыш" мәгънәсе барлыкка килә.

Гомернең билгеле бер чоры да бәхет белән тиңләштерелә. Ул бигрәк тә сабыйлык, балалык һәм яшьлек елларын ала. Тукай шигырьләрендә ул сабыйлык чорына туры килә:

Бәхетле нарасидә! Тар бишек тә киң әле аңар!
Ике ат бер тиен, диңгез тубыктан тиң әле аңгар! (Бишектәге бала).

Хәзерге татар әдәбиятында бәхет ак, зәңгәр төсләр белән янәшә килә.

Күзләргә дә барып кердек инде…
Ак бәхетләр күктән төшмәде,-
Ул бәхетне сары яфрак итеп
Җилле көзләр алга түшәде. (Зөлфәт "ŞŞЯзмыш")

Тукай иҗатында ул чын, зур, берничә урында кара эпитеты белән кулланыла:

Чын бәхетледер кулың тоткан колың;
Гайне кодсият вә гыйффәттер кулың. (Кулың)
Талигым, бәхтем бәнем һәр каралардан карадыр,
Каралык шундан сирайәт әйләмеш бу бәндәми.(Сөальләр)
Нә сәбәбле кәлди безгә бөйлә бер бәхте сияһ?(И каләм)

Әмма бу мисалларда "кара бәхет" күчерелмә мәгънәдә "наданлык" мәгънәсендә килә.

Бәхет концепты метафора һәм фразеологик әйтелмәләр составында тагын да тирәнәя төшә. Бәхет агачы, бәхет диңгезе кебек метафоралар

хәзерге көн поэзия телендә бик актив булса, Тукай иҗатында аның сәгадәт талы, бәхет бәхре вариантлары кулланылыш тапкан:

Сәгадәт талына менсәң, үзең мен;

Ни ярдәм килсә дә килсен үзеңнән. (Тормыш).

Һәр бәхетнең башы шуннан башлана, -

Бер бәхет бәхренә тармактыр кулың. (Кулың).

Борынгы әдәбиятка күз салсак, бәхер сүзен рисаләт, гыйсйан (Мөхәммәдьяр); дөнья (Мәүлә Колый); гөнаһ, мөгасый, әлтаф (Г.Кандалый) сүзләре белән янәшә күрәбез һәм Мөхәммәдьярда нәкъ бу метафора кулланыла [Кадирова 2006,53].

И сәхаwәт мәгдәненең җәүһәри

И сәгадәт тиңезенең гәүһәри (Мөхәммәдьяр, Н.С.45б.);

Бәхетсезлек лексемасы Тукай иҗатында чагыштырмача аз кулланыла. Бу сүз аша да бәхет концептының аерым мәгънәләре ачыла. Шагыйрь бәхетсезлекне ятимлек белән янәшә куя:

Төшсен ләкин исегезгә кайсы вакыт:

Һәркемгә дә бирелмәгән мондый бәхет;

Ятим калган сабыйлар бар, бәхетсезләр,

Ата-анасы вафат, җирсез һәм йортсызлар. (Кышкы кич).

Бәр микән дөн.яда миннән бәхетсезләр?

Хатыным, йортым юк, - ятам номерда. (Бер кайгы көнендә).

Димәк, Тукайча, гаиләле, ата-аналы, йортлы булу – бәхетле булу.

Г.Тукай, бәхеткә каршы, бәхетсезлеккә каршы кереш сүзләрен кулланып, сөйләүченең фикерләренә, тойгыларына уңай бәя бирә: Син белмисеңмени, бу Вәзир үзе жүләр булган; әгәр, бәхетсезлеккә каршы, жүләр башы илә үзе хөкем итсә, никадәр кешеләр күз яшьләре илә һәлак булырлар иде (Вәзир); Күгәрченнең бәхетенә каршы, күзенә бер корган имән күренде (Ике күгәрчен). Бу ике әсәр дә И.А.Крыловның мәсәлләреннән булганлыктан, мисаллар рус теленнән тәрҗемә буларак кергәннәрдер дигән фикер туа. Әлеге кереш сүзләрнең Г.Тукайга кадәр үк кулланылуына татар әдәбиятында

мисал бар: Бәхетсезлегемә каршы, юлчылар арасында сөйләшеп утыруы белән кызыксынырлык бер укыганрак кеше таба алмадым (З.Бигиев. Мавәраэннәһердә сәяхәт).

Бары бер сүз - Бәхет сүзенең Г.Тукай шигырьләрендә кулланылыш үзенчәлекләрен күзәтеп тә, аның иҗатының тирәнлегенә тагын бер мәртәбә инанасың.

## ӘДӘБИЯТ


Амиров Г.С. Синонимы в произведениях Г.Тукая // Тюркская лексикология и лексикография. – М.: Наука, 1971. – С. 47 – 61.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272б.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. - Казан: Тат. кит.нәшр., 1965.-853 б.

Древнетюркский словарь. - Л.: Наука, 1969. - 676 с.

Кандалый Г. Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. – 558б.

Кадирова Э.Х. Концепт «диңгез» в памятниках старотатарской письменности // Тюркология: история и современность. – Казань: ТГГПУ, 2006.- С.52-53.

Мөхәммәдьяр. Нуры содур – Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. – 558б.

Татар теленең анлатмалы сүзлеге. Т. 1. - Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. - 475 б.

Тукай Г. Әсәрләр. Биш томда. – Казан: тат. Кит. нәшр.,